ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«15» декабрь 2021 ел. № 414

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә укудан буш вакытта 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 20 маендагы 142 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, аны Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законы,

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының "Татарстан Республикасында белем һәм квалификация турында документ бирелгән көннән алып бер ел дәвамында урта һөнәри белеме яисә югары белеме булган һәм эш эзләүче 18 яшьтән алып 25 яшькә кадәрге эшсез гражданнарны укудан азат вакытта 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2015 елның 30 ноябрендәге 880 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "2014-2025 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм" дәүләт программасын раслау турында" 2013 елның 09 августындагы 553 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә укудан буш вакытта 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 20 маендагы 142 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Әгерҗе муниципаль районы учреждениеләре, оешмалары, предприятиеләре эшчәнлеге барышында барлыкка килә торган эш урыннары

санын исәпкә алып, 2021 елда Әгерҗе районы буенча «Менделеевск районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесенең филиалы белән берлектә балигъ булмаган гражданнарны каникул һәм укудан буш вакытларында эшкә урнаштыру өчен вакытлыча эш урыннары исемлеге» 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ җитәкчесенә, учреждение, оешма, предприятиеләр директорларына (милек рәвешенә бәйсез рәвештә) Әгерҗе районы буенча «Менделеевск районы халкын эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ филиалына вакытлы эшләр үткәрүне оештыруда әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Баженовага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 20 маендагы 142 номерлы карарына 2 нче кушымта (Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 15.12.2021 № 414 карары редакциясендә)

**Әгерҗе муниципаль районы учреждениеләре, оешмалары, предприятиеләре эшчәнлеге барышында барлыкка килә торган эш урыннары санын исәпкә алып, 2021 елда Әгерҗе районы буенча «Менделеевск районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесенең филиалы белән берлектә балигъ булмаган гражданнарны каникул һәм укудан буш вакытларында эшкә урнаштыру өчен вакытлыча эш урыннары исемлеге**

| № | Милек рәвешләренә бәйсез рәвештә предприятие, оешма, учреждение атамалары | Эш урыннары саны |
|---|---|---|
| 1. | МУП «Төзелеш идарәсе» | 1 |
| 2. | ООО «Нәүрүз» | 4 |
| 3. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең 1 нче гимназиясе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 31 |
| 4. | "Татарстан Республикасы Әгерҗе шәһәренең 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 43 |
| 5. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Таҗи Гыйззәт исемендәге 3 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 41 |
| 6. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең 4 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 20 |
| 7. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениясе | 14 |
| 8. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тирсә урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениясе | 20 |
| 9. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Омга лицее муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 12 |

| | | |
|---|---|---|
| 10. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 2 |
| 11. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районын Красный Бор урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 18 |
| | **БАРЛЫГЫ** | **206** |